Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Ир белән мөгамәлә итү серләре

Икенче басма

Түбән Кама 2010

## Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده و نستعينه و نستغفره و نعوذ بالله من شرور أنفسنا و سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له و من يضلل فلا هادي له و أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له و أشهد أن محمدا عبده و رسوله، أما بعد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ юлы. Барча яңалык — бидгать вә барча бидгать — адашу һәм барча адашу утка илтә.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا الله حَقَّ تُقَاتِهِ وَلا تَمُوتُنَّ إِلا وَأَنْتُمْ مُسْلِمُونَ) آل عمران

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз. Аңа итагать итегез, каршылык вә гөнаһ кылмагыз. Аны зикер кылыгыз һәм онытмагыз. Аңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!».**

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا الله الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ الله كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا) النساء: ١

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халикъ кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәмнең үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен**

**бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен сорагач кешенең кире какмаганлыгын беләсез. Шулай булгач, Аллаһны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаһ бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».**

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللهَ وَقُولُوا قَوْلًا سَدِيدًا ۞ يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَمَنْ يُطِعِ اللهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا) الأحزاب: ٧٠-٧١

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка тәкъва булыгыз, вә хак булган файдалы, дөрес сүзләрне генә сөйләгез! Аллаһ әйткәнчә эш кылсагыз, Аллаһ эшләрегезне вә гамәлләрегезне төзәтер, вә гөнаһларыгызны ярлыкар. Берәү чын күңелдән Аллаһка, вә Аның расүленә итагать итсә, ул кеше һичшиксез өстенлеккә вә изге теләгенә иреште».**

Дөреслектә, Аллаһ тәгалә Үзенең колларына өйләнүне билгеләде һәм кешеләр арасында бозыклык вә фәсәд булмасын өчен, аны гадәти күренеш кылды. Өйләнү ирләр вә хатыннар өчен дә күңел тынычлыгы һәм зинадан саклану чарасы. Ир һәм хатын арасындагы бәхетнең вә шатлыкның хакыйкатькә чыгуын өстәп һәм дә алар арасындагы нәфрәт вә күңелсезлекләрне бетерүгә бер сәбәп булсын дип, ошбу язмаларны тәкъдим итәргә булдым. Без инде монда иң яхшы вә күркәм нәсыйхәтләрне генә җыярга тырыштык. Аллаһ Раббыбыз ошбу эшләребезне Үзенең ризалыгы өчен ихлас кылып, динебезгә файдалы гамәлләрдән әйләсә иде. Бу китапта булган аз гына тырышлык, хәерлесе вә дөресе Аллаһ тәгаләдән:

(وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُنْ تَعْلَمُ) النساء: ١١٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ сиңа белмәгәнеңне өйрәтте».**

(وَلا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلا بِمَا شَاءَ) البقرة: ٢٥٥

Мәгънәсе: **«Аллаһ гыйлеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ теләгәнне генә белерләр».**

Ә инде китапта хата вә кимчелек булса — минем үземнән вә шәйтаннан:

(قُلْ هُوَ مِنْ عِنْدِ أَنْفُسِكُمْ) آل عمران: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Бу үзегезнең нәфсегездән», — диген».**

(وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِلْإِنْسَانِ خَذُولا) الفرقان: ٢٩

Мәгънәсе: **«Шәйтан кешегә батылны матурлап вә хакны кабахәт кылып, алдап ташлап китәр булды».**

Аллаһ тәгалә барчабызга һидәят-тәүфыйк бирсен. Кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсен.

Я Раббым, безне Үзеңнең туры юлыңнан алып бар, хакны хак итеп белгерт һәм безне хаклыкка якынайт, батылны батыл итеп белгерт һәм безне батылдан ерагайт. Коръән вә Сөннәткә тотынучылардан кыл һәм ихлас-тәкъва бәндәләреңнән әйләп, Үзеңнең рәхмәтең белән Фирдәвес Җәннәтләреңә керт. Әмин.

*Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи*

*Хатлар өчен:* **mullaniyaz@mail.ru**

# ИР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ИТҮ СЕРЛӘРЕ

## 🕮 Иреңне ничек сайлыйсың?

Иреңне сайлаганда бик тә игътибарлы бул! Чөнки, гаилә тормышы үзара аңлашу, ярдәмләшү һәм мәхәббәтсез дәвам итә алмый.

Пәйгамбәребез ﷺ кызларга тормыш иптәшләрен сайлауда нәсыйхәт итеп болай диде:

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ الله عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «إِذَا خَطَبَ إِلَيْكُمْ مَنْ تَرْضَوْنَ دِينَهُ وَخُلُقَهُ فَزَوِّجُوهُ إِلا تَفْعَلُوا تَكُنْ فِتْنَةٌ فِي الأَرْضِ وَفَسَادٌ عَرِيضٌ» [ الترمذي ١٠٨٤ تحقيق الألباني: حسن ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә сезнең кызларыгызга өйләнергә дип, дине һәм холкы риза булырлык берәү килеп сораса, аны (кызларыгызга) өйләндерегез! Өйләндермәсәгез җир йөзендә фетнә һәм зур фәсәд таралыр».***

Бервакыт, Хәсән әл-Бәсрый янына бер кеше килеп: «Минем бик тә яраткан бердәнбер кызым бар, кемгә аны кияүгә бирим икән?», — дип сорагач, ул аңа: «Аллаһ тәгаләгә тәкъва кешегә кияүгә бир, әгәр дә ул хатынын яратса — аңа киң күңелле булыр, яратмаса — золым кылмас һәм рәнҗетмәс», — диде.

Мару шәһәрендә казый булып торучы Нух бин Мәрьям үзенең кызын кияүгә бирергә теләгәч, мәҗүси күршесеннән: «Кызымны кемгә бирим икән?», — дип сорый. Мәҗүси күршесе аңа: «Кызык, синең үзеңнән хөкем сорыйлар, ә син миннән сорыйсың?», — дип аптырый. Казый аңа: «Син бит минем күршем, син миңа яхшы киңәш бирергә тиешсең», — ди. Мәҗүси: «Фарсыларның патшасы Кисра — байлыкны сайлый иде, Румнарның патшасы — Кайсар, матурларны һәм яхшы нәселләрне сайлый иде, ә сезнең рәисегез Мөхәммәд — динне сайлый иде. Шулай булгач, үзең кара, кайсысыннан син үрнәк аласың?!», — диде.

## 🕮 Ирең өчен зиннәтлән вә бизән!

Син ирең өчен гүзәл һәм иң хуш исле гөлчәчәк кебек бул! Әгәр дә ул сиңа караса — аның күңеле шатлансын.

عن ابن عباس قال: «نساؤنا يختضبن أحسن خضاب يختضبن بعد العشاء و ينزعن قبل الفجر» [ مصنف ابن أبي شيبة صحيح من قول ابن عباس ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵁ әйтте: ***«Безнең хатыннарыбыз ястүдән соң иң матур бизәнү белән бизәнәләр һәм иртәнге намаз алдыннан юуып бетерәләр иде».***

عن علقمة: «أنه كان يأمر نساءه يختضبن في أيام حيضهن» [ أخرجه البيهقي في السنن الكبرى ٧٧/١ صحيح عن علقمة ]

Мәгънәсе: Галкама ﵁ хатыннарына күрем вакытында бизәнү буяулары белән бизәнергә әмер итә иде.

Үмәмәһ бинт әл-Хәрис үзенең кызын кияүгә бирер алдыннан болай дип нәсыйхәт итә торган иде: «Иреңнең күзенә беркайчан да ямьсез, бизәнмәгән хәлдә күренмә һәм ул беркайчан да синнән начар ис килгәнен сизмәсен!».

Шулай ук Габдуллаһ бин Җәгъфар кызының никахы алдыннан аңа нәсыйхәт биреп: «Син һәрвакытта да зиннәтлән һәм иң яхшы зиннәт, ул — сөрмә, ә иң яхшы хушбуй, ул — су», — дип әйтә торган иде.

## 🕮 Иреңне җәфалама вә йөдәтмә!

Изге-салих ир, ул сиңа Аллаһның нигъмәте. Шуның өчен дә аңа карата бик тә ихтирамлы бул, чөнки ул сиңа бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешүнең сәбәбе булып тора!

عن معاذ بن جبل رضي الله عنه عن النَّبيِّ ﷺ قَالَ: «لاَ تُؤْذِي امْرَأَةٌ زَوْجَهَا في الدُّنْيَا إلاَّ قَالَتْ زَوْجَتُهُ مِنَ الحُور العِينِ: لاَ تُؤذِيهِ قَاتَلَكِ اللهُ! فَإنَّمَا هُوَ عِنْدَكِ دَخِيلٌ يُوشِكُ أنْ يُفَارِقَكِ إلَيْنَا» [ رواه الترمذي ١١٧٤ وَقالَ: حديث حسن ]

Мәгънәсе: Мүгаз бин Җәбәлдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бу дөньяда хатын-кыз үзенең ирен җәфаласа, аның хур***

***кызларыннан булган хатыны: «Аны җәфалама, Аллаһ сине ләгънәтләсен! Ул бары тик синең кунагың гына, тиздән ул синнән китеп безгә килер!», — дип әйтә».***

Икенче риваятьтә: ***«Өч кешенең догасы кабул булмый...*** (шуларның берсе) ***начар холыклы хатыны булып, аны талак кылмаган ир»,*** — диелде[1].

Дауыд عليه السلام болай диде (дөреслеген Аллаһу әгъләм): «Начар холыклы хатын, карт бабайга бик тә авыр йөк күтәргән кебек».

Локман-хәким улын нәсыйхәт итеп болай диде: «Әй улым! Начар холыклы хатыннардан саклан, чөнки алар синең чәчеңне вакытыннан алда агартачаклар һәм явыз хатыннардан саклан, чөнки алар изгелеккә өндәмиләр».

## Һәҗәр кебек бул!

Иман — ул тормышның рухы вә җаныдыр. Имансыз гаилә — һавадагы мамык кебек, аның ныклыгы юк. Җил аны кайсы якка очырса, ул шул якка оча. Шуңа да гаиләңне төзегәндә, ныклы иманга нигезләп төзе!

Ибраһим عليه السلام Һәҗәр радый Аллаһу ганһәне күкрәк баласы белән бергә, сусыз, ризыксыз вә кешесез Мәккә чүллегенә алып килеп калдыргач, Һәҗәр аңа: «Әй Ибраһим! Син безне суы да, ризыгы да булмаган чүллектә ничек калдырып китәсең, Аллаһ сиңа шулай әмер иттеме?», — дип сорагач, Ибраһим عليه السلام аңа: «Әйе», — дип җавап бирде. Шуннан соң Һәҗәр тынычланып: «Алайса, Аллаһ безне һәлак итмәс», — диде.

***Хикәя:*** Изге сәләфләрдән булган бер ир хатынына да, балаларына да бернәрсә дә калдырмыйча җиһәдкә чыгып киткәч, аның хатынына: «Ничек инде ирең сезгә бернәрсә дә калдырмыйча, син аңа чыгып китәргә рөхсәт иттең?», — диелгәч, ул: «Мин иремне Ризыкландыручы дип белмим, ул ашаучы гына.

---

1 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйрь вә Зиядәһ» (шәйх Әлбәний сахих диде)

Ашаучы китсә дә, аңа карап Ризыкландыручы беркемне дә ризыксыз калдырмый!», — дип җавап бирде.

## Иреңә елмаеп кара!

Елмаю, ир белән хатын арасына өлфәт салуга сәбәптер. Шуңа да, ирең һәрвакыт сиңа караганда, синең йөзеңдә елмаю күрсен!

عن أَبي ذَرٍّ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ لي رسول الله صلى الله عليه وسلم: «لاَ تَحْقِرَنَّ مِنَ الْمَعْرُوفِ شَيْئاً وَلَوْ أَنْ تَلْقَى أَخَاكَ بوَجْهٍ طَلْقٍ» [ مسلم ٢٦٢٦ ]

Мәгънәсе: Әбү Зәрр ؓ әйтте: «Бервакыт, пәйгамбәребез ﷺ миңа: ***«Шәригатьтә хәерле булган нәрсәләргә, хәтта кардәшеңне шатлыклы йөз белән каршы алу тиешле булуына да, беркайчан да ваемсыз булма»,*** — диде».

## Иреңнең шатлыкларын да, кайгыларын да уртаклаш!

Иреңнең тойгыларын хөрмәт ит һәм аның шатлыгын да, кайгысын да уртаклаш.

Хәдиҗә радый Аллаһу ганһә иренең тойгыларын вә хисләрен хөрмәт итүдә һәм уртаклашуда барча хатыннарга да үрнәк булып торды. Ул пәйгамбәребез ﷺ белән бәхетле вә шатлыклы көннәр тормыш итте һәм расүлебезгә ﷺ вахи иңгәч аны юатып: «Хакыйкатьтә, Аллаһ белән ант итәм! Аллаһ сине беркайчан да хурлыкка төшермәячәк!», — диде. Шуннан соң ул вафат булганчыга кадәр, пәйгамбәребезгә ﷺ Аллаһның динен башкаларга җиткерүдә, барча авырлыкларны да аның белән уртаклашуда ярдәмче булды.

Үмәмәһ бинт әл-Хәрис кызын кияүгә биргәндә болай дип нәсыйхәт кыла торган иде: «Иреңнең кайгысында шатланудан саклан һәм аның шатлыгында кайгы белдерүдән саклан!».

## 🕮 Хәләл ризык кәсеп итүдә иреңә ярдәмче бул!

***«Хәрам белән үскән һәрбер тән әгъзасына, Җәһәннәм уты әүвәлерәк»[2].*** Шуңа да, иреңә хәләл ризык кәсеп итүдә ярдәмче бул!

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّ اللهَ طَيِّبٌ لاَ يَقْبَلُ إِلاَّ طَيِّبًا وَإِنَّ اللهَ أَمَرَ الْمُؤْمِنِينَ بِمَا أَمَرَ بِهِ الْمُرْسَلِينَ فَقَالَ: (يَا أَيُّهَا الرُّسُلُ كُلُوا مِنَ الطَّيِّبَاتِ وَاعْمَلُوا صَالِحًا) [ المؤمنون: ٥١ ] وَقَالَ (يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُلُوا مِنْ طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ) [ البقرة: ١٧٢ ] ثُمَّ ذَكَرَ الرَّجُلَ يُطِيلُ السَّفَرَ أَشْعَثَ أَغْبَرَ يَمُدُّ يَدَيْهِ إِلَى السَّمَاءِ يَا رَبِّ يَا رَبِّ وَمَطْعَمُهُ حَرَامٌ وَمَشْرَبُهُ حَرَامٌ وَمَلْبَسُهُ حَرَامٌ وَغُذِىَ بِالْحَرَامِ فَأَنَّى يُسْتَجَابُ لِذَلِكَ» [ مسلم ١٠١٥ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әй кешеләр, дөреслектә, Аллаһ — Яхшы һәм Ул яхшыдан башка бернәрсәне дә кабул итми һәм дөреслектә, Аллаһ илчеләргә әмер иткәнне мөэминнәргә дә әмер итте һәм Аллаһ тәгалә әйтте:* «Әй илчеләр! Яхшыны ашагыз һәм изге гамәлләр кылыгыз».** ***Аллаһ тәгалә шулай ук әйтте:*** **«Әй иман китергән бәндәләр! Без сезне ризыклаган яхшы нәрсәләрне ашагыз...».** Әбү Һурайра ﵁ әйтте: «Ә аннан соң пәйгамбәребез ﷺ тузан белән капланган, тырпайган чәчле, озак сәфәрдәге кеше турында зикер итте, ул: «Әй Раббы!», — дип кабатлап кулларын күккә күтәрә» һәм расүлебез ﷺ әйтте: ***«Әмма аның ризыгы хәрам, эчемлеге хәрам, киеме хәрам һәм хәрам белән тәрбияләнгән, ничек соң аның догасына җавап бирелсен?!».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رَضِى اللهُ عنه عَنِ النَّبِىِّ ﷺ قَالَ: «يَأْتِى عَلَى النَّاسِ زَمَانٌ لاَ يُبَالِى الْمَرْءُ مَا أَخَذَ مِنْهُ أَمِنَ الْحَلاَلِ أَمْ مِنَ الْحَرَامِ» [ البخاري ٢٠٥٩ ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кешеләргә шундый заманалар җитәр, алар хәләлдәнме яки хәрамнанмы алынганлыкка игътибар бирми башларлар».***

Изге сәләфләрнең хатыннары, ирләре иртә белән эшкә вә кәсеп итәргә чыгып киткәндә аларга: «Әй Аллаһның колы!

---

2 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйрь вә Зиядәһ» 8648 (шәйх Әлбәний сахих диде)

Хәрам кәсеп итүдән саклан һәм хәләлне генә кәсеп ит! Чөнки без ачлыкка вә авырлыкка сабыр итәрбез, ә инде Җәһәннәм утына вә Раббыбызның ачуына сабыр итә алмабыз!», — дип әйтә торган иделәр.

***Хикәя:*** «Бервакыт, Мәдинә шәһәренең базарында бер хатын-кыз мең динар белән калта[3] таба. Өенә кайтып бу хәлне иренә сөйләп бирә. Ире инде: «Без бик мохтаҗ идек әле бу акчага», — дип, акчаларны үзләштермәкче булгач, хатыны аңа: «Без бу акчаларны үзебезгә ала алмыйбыз, син базарга бар да: «Бүген акча табылды, югалткан кеше акчаның күләмен, нинди нәрсәдә вә башка галәмәтләрен әйтеп бирсен», дип игълан яса», — ди. Ире хатынының сүзен тыңлап базарга китә һәм анда игълан ясаганнан соң, аның янына берәү килеп: «Мин бүген атта барганда, минем кызыл төстәге калтам белән мең динар төшеп югалды», — дип, барча галәмәтләрне дә әйтеп бирә. Акчаны тапкан хатынның ире: «Бүген бу калтаны минем хатыным табып алган, бу синеке булса каирәк», — дип аңа акчаларны бирә. Калтаның хуҗасы: «Хакыйкатьтә, бу садака акчалары, мин бүген аларны мохтаҗ кешеләргә бирермен дип чыккан идем, ул сезнеке», — дип акчаларны аңа кире бирә.

## 🕮 Ireңнән канәгать бул!

Хатын-кызның иреннән канәгать булуы, бу дөньяда да, ахирәттә дә аны бәхет-сәгадәткә ирештерә. Хатын-кызның матурлыгы да, бай булуы да һәм затлы нәселдән булуы да, аны башка ят ирләргә карарга этәрергә тиеш түгел! Аллаһ ﷻ Җәннәт хатыннарын ошбу сыйфатлар белән сыйфатлап болай диде:

(فِيهِنَّ قَاصِرَاتُ الطَّرْفِ) الرحمان: ٥٦

Мәгънәсе: **«Вә ул Җәннәттә үз ирләреннән башка иргә күз төшерми торган хур кызлары бар».**

3 Акча янчыгы

Ибен Габбас ﵁ бу аятьне аңлатып болай диде: «Ул хатыннар Җәннәттә ирләреннән дә яхшырак башка бернәрсә дә күрмәсләр, ягъни аларның ирләре аларга иң күркәмнәре булырлар». Ибен Кәсир тәфсирендә дәвам итеп: «Ул Җәннәт хатыннарының берсе иренә: «Аллаһ белән ант итәм! Мин Җәннәттә синнән дә яхшырак бернәрсә дә тапмыйм һәм монда миңа синнән дә сөйкемлерәк һичнәрсә дә юк, әлхәмдүлилләһ, Аллаһ тәгалә сине миңа бар кылды һәм мине сиңа бар кылды», — дип әйтер», — диде.

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضي الله عَنْهُ قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «أُرِيتُ النَّارَ فَإِذَا أَكْثَرُ أَهْلِهَا النِّسَاءُ يَكْفُرْنَ» قِيلَ: أَيَكْفُرْنَ بِاللَّهِ؟ قَالَ: «يَكْفُرْنَ الْعَشِيرَ وَيَكْفُرْنَ الإِحْسَانَ لَوْ أَحْسَنْتَ إِلَى إِحْدَاهُنَّ الدَّهْرَ ثُمَّ رَأَتْ مِنْكَ شَيْئًا قَالَتْ مَا رَأَيْتُ مِنْكَ خَيْرًا قَطُّ» [ البخاري ٢٩ ]

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Миңа Җәһәннәм күрсәтелде һәм анда иң күбе көферлек кылган хатын-кызлар булды».*** Шуннан соң сорадылар: «Алар Аллаһка көферлек кылганнармы?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Алар ирләренә һәм аларга карата күрсәтелгән ихсанга рәхмәтле булмаганнар. Әгәр дә син ул хатыннарга гомер буе ихсанлы, яхшы булсаң да һәм шуннан соң синдә бер генә булса да аңа ошамаган әйбер күрсә, ул сиңа: «Мин синнән гомер буе изгелек күрмәдем», — дип әйтер».***

## Иреңнең фәкыйрьлегенә сабыр ит!

Фәкыйрьлек, ул кешенең кимчелеге түгел, бәлки аңа сабыр булмау вә фәкыйрьлектән чыгу юлларын эзләмәү — кимчелеккә керәдер.

عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ اللهُ عَنْهَا قَالَتْ: «مَا شَبِعَ آلُ مُحَمّد صلى الله عليه وسلم مِنْ خُبْزِ شَعِيرٍ يَوْمَيْنِ مُتَتَابِعَيْنِ حَتَّى قُبِضَ» [ مسلم ٢٩٧٠ ] وفي رواية: «مَا شَبِعَ آلُ مَحَمّد صلى الله عليه وسلم مُنْذُ قَدِمَ المَدِينَةَ مِنْ طَعَامِ البُرِّ ثَلَاثَ لَيَالٍ تِبَاعاً حَتَّى قُبِضَ» [ البخاري ٥٤١٦ ]

Мәгънәсе: Гаишә әйтте: ***«Мөхәммәднең ﷺ үлеменә кадәр, аның гаилә әһелләре беркайчан да арпа икмәген ике көн тоташтан туйганчы ашамадылар».***

Икенче риваятьтә: ***«Мөхәммәд ﷺ Мәдинәгә килеп, үлеме ирешкәнчегә кадәр аның гаилә әһелләренә беркайчан да өч төн (көн) тоташтан туйганчы бодай икмәге ашарга туры килмәде».***

عِن ابن عباس رضي الله عنهما قَالَ: «كَانَ رسول الله ﷺ يَبيتُ اللَّيَالِيَ الْمُتَتَابِعَةَ طَاوِياً وَأَهْلُهُ لاَ يَجِدُونَ عَشَاءً وَكَانَ أَكْثَرُ خُبْزِهِمْ خُبزَ الشَّعيرِ» [ رواه الترمذي وقَالَ: حديث حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﷺ: ***«Еш кына пәйгамбәребезгә ﷺ берничә көн тоташтан ач килеш йокларга туры килә иде, шулай ук аның гаилә әһелләре дә кичке ашка үзләренә бернәрсә дә таба алмыйлар иде, ә алар ашаган икмәк күбрәк арпадан була торган иде».***

Бервакыт Габдуррахман бин Гауф ﵁ ураза хәлендә булганда, аңа ризык китерделәр һәм ул ризыкны күреп: «Хәмзә ﵁ үтерелгәч, аны кәфеннәргә бер кисәк чүпрәктән башка бернәрсә дә тапмадылар, шулай ук Мүсгаб бин Гумайр үтерелгәч тә аны да кәфеннәргә бер кисәк чүпрәктән башка һичнәрсә дә тапмадылар. Безнең яхшы ризыкларыбыз бу дөньяда ук бирелеп бетәр дип куркам», — диде дә, елый башлады.

## Иреңнең кунакларына әһәмиятле бул!

Иреңнең кунакларына бик тә әһәмиятле бул, чөнки аның кунакларына әһәмият бирүең — иреңне ихтирам итүең була.

عن أَبي هريرة رضي الله عنه: أَنَّ النبيَّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَنْ كَانَ يُؤْمِنُ بِاللهِ وَاليَوْمِ الآخِرِ فَلْيُكْرِمْ ضَيْفَهُ...» [ متفقٌ عَلَيْهِ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһка һәм Кыямәт көненә иман китергән кеше, кунагына юмарт вә яхшы булсын...».***

Бервакыт, пәйгамбәребезгә ﷺ ниндидер кеше килеп: «Дөреслектә, мин хәлсезләндем!»[4], — диде. Пәйгамбәребез ﷺ бер кешене үзенең хатыннарының берсенә җибәрде, ләкин хатыны: «Сине хаклык белән җибәргән Зат белән ант итәм, минем судан башка бернәрсәм дә юк!», — диде. Аннан ул аны икенче хатынына җибәрде, ләкин ул да шундый ук сүзләрне әйтте, ахырда ул бөтен хатыннарын әйләнеп чыкты, ләкин алар барысы да: «Сине хаклык белән җибәргән Зат белән ант итәм, минем судан башка бернәрсәм дә юк!», — дип, шул ук сүзне әйттеләр. Шунда пәйгамбәребез ﷺ: ***«Кем бу кешене бүген кичкә үзенә ала?»,*** — дип сорады. Әнсарлардан берәү: «Мин, әй Аллаһның илчесе», — диде. Шуннан соң ул аны үз өенә алып кайтты һәм хатынына: «Расүлебезнең ﷺ кунагына хөрмәт күрсәт», —диде.

Икенче риваятьтә: Бу әнсар хатыныннан: «Синең ашарга берәр нәрсәң бармы?», — дип сорады. Ул: «Балаларым өчен әзерләнгән ризыктан башка бернәрсә дә юк!», — диде. Ул: «Аларны берәр нәрсә белән шөгыльләндер, әгәр ашарга теләсәләр аларны йокларга яткыр, кунак кергәч утны сүндер һәм без дә ашаган кебек булып утырыйк», — диде. Ә аннан соң алар үз урыннарына утырдылар, кунак ашады, ә алар ач килеш йокларга яттылар. Иртән йорт хуҗасы пәйгамбәребез ﷺ янына килде, пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Сезнең бу кичтә кунак белән нәрсә кылганыгызны күреп Аллаһ гаҗәпләнде!»,*** — диде». Һәм Аллаһ тәгалә ошбу аятьне иңдерде, мәгънәсе: **«Алар үзләре мохтаҗ булсалар да, башкаларга бирүне артыграк күрәләр. Берәү нәфесенең бик саранлыгыннан сакланса, андый кешеләр ахирәттә өстенлек тапкан кешеләрдер»[5].**

4 Ачлыктан вә арудан

5 Бухари (3798)

## 🕮 Ирең каршында булган хакны үтәүдә ваемсыз булма!

Иреңнең синең каршында булган бурычларына караганда, үзеңнең аның каршында булган бурычларны үтәүне алгарак куй! Чөнки ирең — синең Җәннәтең һәм Утың!

Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына бер хатын килеп үзенең кирәк-ярак сорауларын сорап хаҗәтләрен үтәгәннән соң, расүлебез ﷺ аннан: ***«Син кияүдәме?»,*** — дип сорады. Ул хатын: «Әйе», — дип җавап бирде. Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ: ***«Син аның белән ничек мөгамәлә итәсең?»,*** — дип сорады. Ул хатын: «Көчемнән килгәнчә мин аның каршында булган бурычларымны җиренә җиткереп үтәргә тырышам, иллә-мәгәр көчемнән килмәгәнен генә үти алмыйм», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Син ирең янында үзеңнең кем икәнеңне бел, ул синең Җәннәтең дә, Утың да!»,*** — диде[6].

Гаишә радый Аллаһу ганһә: «Әй хатыннар! Әгәр дә сез ирләрегезнең хакларын белсәгез, сез аларның аякларындагы тузаннарын йөзегез белән сөртер идегез!», — диде[7].

Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына Әсмә бинт Язид радый Аллаһу ганһә килде дә: «Минем атам вә анам сиңа фидә булсын әй расүл Аллаһ! Мин сиңа бер төркем хатын-кызлардан вәкил булып килдем... Аллаһ тәгалә сине ирләргә дә, хатыннарга да хаклык белән җибәрде һәм без сиңа да, сине пәйгамбәр итеп җибәрүче Аллаһка да иман китердек. Без — хатын-кызлар үзебезне кимсетелгән дип уйлыйбыз, өйдә генә утырабыз, сезнең шәһвәтләрегезне басабыз һәм балаларыгызны күтәреп йөрибез. Ә сез — ирләр, безгә караганда җомга белән дә, җәмәгать белән дә, авыруларны зиярат итү белән дә, җеназа озату белән дә, хаждан соң хаҗ кылып та һәм болардан да яхшырак булган — Аллаһ юлында җиһәд кылу белән дә бездән өстенрәк булдыгыз. Без ничек сезнең белән бергә әҗер-савап эшли алыйк, әй Аллаһның илчесе?», — дип сора-

6 Мүснәд Әхмәд (шәйх Арнәуут һәм Әлбәний хәсән диделәр)
7 Мусаннаф Ибен Әби Шәйбәһ

ды. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Үзең белән бергә булган барча хатыннарга да әйт: Сезнең берегезнең ире белән яхшы мөгамәлә итеп, аның ризалыгын алуы һәм аңа ярарга тырышуы, боларның барча савабына да тиң була»,*** — диде. Бу сүзләрне ишеткәч ул хатын шатлыгыннан тәкбирләр әйтә-әйтә чыгып китте[8].

## 🕮 Ирең чакырса җавап бир һәм аны ачуландырма!

Әгәр дә сине ирең ятакка чакыра икән, син аны инкяр итмә һәм ireңнең сиңа ачуланып төн үткәрүеннән саклан! Ирең ачулана торган булса, аны тынычландыруга вә канәгатьләндерүгә ашык! Чөнки ireңнең ачуына фәрештәләр сиңа ачулана.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «إِذَا دَعَا الرَّجُلُ امْرَأَتَهُ إِلَى فِرَاشِهِ فَأَبَتْ فَبَاتَ غَضْبَانَ عَلَيْهَا لَعَنَتْهَا الْمَلَائِكَةُ حَتَّى تُصْبِحَ» [ البخاري ٣٢٣٧ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә ире хатынын үзенең янына ятакка чакырса һәм хатыны аны инкяр итеп, ире аңа ачуланган хәлдә төн чыкса, ул хатынны фәрештәләр иртәнгә кадәр ләгънәт кылыр».***

عن ابن عمر رضي الله عنهما قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «اثْنَانِ لا تُجَاوِزُ صَلاتُهُمَا رُءُوسَهُمَا: عَبْدٌ آبِقٌ مِنْ مَوَالِيهِ حَتَّى يَرْجِعَ إِلَيْهِمْ، وَامْرَأَةٌ عَصَتْ زَوْجَهَا حَتَّى تَرْجِعَ» [ المستدرك على الصحيحين للحاكم ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ике төрле кешенең намазы баш өсләреннән артык күтәрелми (ягъни кабул булмый); хуҗасыннан качкан кол — хәтта кире кайтканчыга кадәр һәм иренә буйсынмаган хатын — хәтта тәүбә иткәнчегә кадәр[9]».***

Бер ана үзенең кызын нәсыйхәтләп болай диде: «Әй кызым! Әгәр дә сине ирең ятакка чакыра икән — җавап бир вә ин-

8 «Шүгүб әл-Иман» әл-Бәйһәкый

9 Ягъни тәүбә итеп, ире аннан риза булганчыга кадәр

кяр итмә! Бу буйсынуда сиңа берничә файда бар: 1) Ирең чит хатын-кызларга карамас. 2) Аның алдында булган бурычыңны үтисең. 3) Үзеңне ләгънәттән саклыйсың һәм савап аласың.

Изге сәләфләрдән булган бер хатын-кыз ястү намазын укыганнан соң, иреннән: «Миндә хаҗәтең бармы?», — дип сорый торган иде. Әгәр дә иренең хаҗәте булса — үти торган иде, ә инде булмаса — таһәрат алып төне буе намаз укып чыга иде.

## Гомәр رضي الله عنه вакытындагы сөт сатучы кыз кебек бул!

Аллаһ белән үзеңнең арадагы һәм ирең белән үзеңнең арадагы булган юлны, ихласлылык вә тугрылык белән нурландыр! Һәм дә Гомәр رضي الله عنه вакытындагы сөт сатучы кыз кебек бул!

Көннәрнең берендә, Гомәр رضي الله عنه мөселманнарның хәл-әхвәлләрен белешеп урамда йөргәндә, кызына сөткә су кушарга боерган хатын-кызның тавышын ишетеп калды. Моңа җавап итеп бу кыз әнисенә: «Мөэминнәрнең әмире Гомәр رضي الله عنه сөтне су белән бутамаска кушты», — диде. Әнисе кызына: «Әй кызым! Безне бит Гомәр күрми», — дигәч, кызы: «Гомәр безне күрмәсә дә, безне Гомәрнең Раббысы күрә», — дип җавап бирде. Бу сүзләрне ишетеп торган Гомәр, бу кызның изгелеген вә диндарлыгын күреп, үзенең улы Гасыймны бу кызга өйләндерде һәм аларның киләчәк буыныннан Гомәр бин Габдулгазиз дөньяга килде.

Син дә ошбу кыз кебек ихлас вә тугры бул һәм: «Ирем күрмәсә дә, иремнең Раббысы булган Аллаһ күрә», — дип, үзеңне гөнаһтан читләштер!

## 🕮 Ирендә чит хатын-кызларны сыйфатлама!

Иреңә башка хатын-кызларны сыйфатлаудан саклан! Чөнки шәйтан бу сүзләрне аның күңеленә вәсвәсә итеп салуы бик тә ихтимал.

عن ابن مسعودٍ رضي الله عنه قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «لاَ تُبَاشِرِ المَرْأَةُ المَرْأَةَ فَتَصِفَهَا لِزَوْجِهَا كَأَنَّهُ يَنْظُرُ إِلَيْهَا» [ البخاري ٥٢٤٠ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгудтан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бер хатын-кыз да башка хатын-кызның тәненә карап яки кагылып һәм аннан соң аны иренә, ире күз алдында ул хатынны күреп торган кебек итеп сыйфатламасын».***

***Хикәя:*** Безнең авылларыбызда чегәннәр нәрсә дә булса сатып йөрүләре беркемгә дә гаҗәеп түгел.

Менә шулай бер чегән хатыны өйдән өйгә кереп хатын-кызларга күлмәкләр сатып йөри икән. Аның тәкъдим иткән күлмәкләренең яраганлыгын белер өчен, алырга теләүче хатыннар өсләренә киеп карый торган булганнар. Көннәрнең берендә бу чегән хатыны баерак кешеләргә кереп күлмәкләрен тәкъдим итә. Йорттагы хатын-кызлар күлмәкне киеп караганда, бу чегән хатыны йорт хуҗабикәсенең тәнендә зур гына миң күреп ала һәм кайтып иренә сөйләп бирә. Чегән иренең башына ялт итеп явызлык килә һәм бай хуҗага барып: «Миңа акча бирмәсәң, мин синең хатының белән йоклаганны барчасына да сөйлим, минем йоклавыма дәлил булып, синең хатыныңның тәнендә (яшеренрәк урынында) зур миң барлыгын беләм», — дип, куркыта башлый...

Хикәянең ахыры безнең өчен бик мөһим түгел, әмма безгә мөһим булганы: Без ят кешеләргә гаурәтләребезне күрсәтергә тиеш түгел, әгәр дә ялгыш кем дә булса башка берәүнең гаурәтен күрде икән, аны һичкемгә дә сөйләргә хакы юк!

## Исраф кылучылардан булма!

Акчада да, ризыкта да исраф кылучылардан булып, иреңә авыр йөк кебек булма! Чөнки синең исраф кылуың, иреңне бурычлы итүгә яки гөнаһка яки хәрамга этәрүе бик ихтимал.

(وَكُلُوا وَاشْرَبُوا وَلَا تُسْرِفُوا إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ) الأعراف: ٣١

Мәгънәсе: **«Ашагыз вә эчегез, ләкин исраф кылмагыз, тәхкыйк, Аллаһ исраф итүчеләрне сөйми».**

(إِنَّ الْمُبَذِّرِينَ كَانُوا إِخْوَانَ الشَّيَاطِينِ وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِرَبِّهِ كَفُورًا) الإسراء: ٢٧

Мәгънәсе: **«Малны исраф итүчеләр, әлбәттә, шәйтан кардәшләредер, ә шәйтан Раббысына кәфер булды».**

Гаишә радый Аллаһу ганһәдән риваять кылуынча: «Бервакыт, Һинд (Әбү Суфиянның хатыны) пәйгамбәребездән ﷺ сорады: «Хакыйкатьтә, Әбү Суфиян саран кеше, мин аңа әйтмичә аның малыннан алсам ярыймы?». Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Үзеңә һәм балаларыңа җитәрлек тиешлесен генә ал!»,*** — диде.

## Иреңнең яшерен серләрен таратма!

Иреңнең гамәлләре һәм сүзләре сиңа әманәт итеп бирелгән, шуңа да аны башкаларга таратудан сак бул!

عن أَبي سعِيد الخدري رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ الله صلى الله علِيه وسلم: «إِنَّ مِنْ أَشَرِّ النَّاسِ عِنْدَ الله مَنْزِلَةً يَوْمَ الْقِيَامَةِ الرَّجُلَ يُفْضِي إِلَى امْرَأَتِهِ وَتُفْضِي إِلَيْهِ ثُمَّ يَنْشُرُ سِرَّهَا» [ مسلم ١٤٣٧ ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөреслектә, Кыямәт көнендә Аллаһ каршында иң начар хәлләттә булган кешеләр арасында, хатыны белән төн кунып, соңыннан алар арасында булганнарның барысы турында да башкаларга сөйләүче ир булыр».***

Бу хәдистә ирләр дип әйтелсә дә, ләкин ул хатыннарга да кагыла.

Шулай ук, Аллаһ тәгалә Коръәндә Нух һәм Лутның ﷺ хатыннары хакында да бик каты кисәтеп гыйбрәт кылды.

Мәгънәсе: **«Аллаһ мисал итеп, хакны инкяр итүче кәферләргә, Нух пәйгамбәрнең хатынын вә Лут пәйгамбәрнең хатынын зикер итте. Бу ике хатын, Безнең ике изге колларыбызның кул астында иделәр, бу ике хатын үзләренең ирләре булган пәйгамбәрләргә хыянәт иттеләр, ирләренә зарар итәргә теләделәр. Бу ике хатынны Аллаһ газабыннан һичнәрсә коткара алмады. Вә ул хатыннарга, утка керүчеләр белән бергә утка керегез, дип әйтелде».** «Әт-Тәхрим» 10

Нух пәйгамбәрнең хатыны кешеләргә иренең серләрен сөйли торган иде. Әгәр дә берәү Нухка иман китереп ияргә торган булса, ул хатын бу кешене Нухка ияргүдән туктатыр өчен, ялт итеп кәферләргә чыгып сөйли иде.

Ә инде Лут пәйгамбәрнең хатыны, иренә килгән кунакларны кәферләргә яшерен генә чыгып әйтә торган иде.

Үмәмәһ бинт әл-Хәрис кызына нәсыйхәт итеп: «Иреңнең серләрен беркемгә дә сөйләмә, әгәр дә аның серләрен сөйләсәң, ул сөйләнгән серләрнең явызлыгыннан имин була алмассың», — дип әйтә торган иде.

***Хикәя:*** Гарәп әдәбият китапларында шундый хикәя килә: «Бер ир үзенең игенлек җирендә җир сөреп йөргәндә, алтын тулы чүлмәк таба. Бу чүлмәкне өенә алып кайтып хатынына күрсәтим дигәндә, башына «хатыннар сер тотмый» дигән уй килә һәм хатынын тикшереп карамакчы булып, үзе белән йомырка алып керә дә, ятагы янына яшереп куя. Иртә белән торгач хатынын уятып: «Әгәр дә син беркемгә дә сөйләмәскә сүз бирсәң, мин сиңа бер сер әйтәм», — ди. Хатыны: «Беркемгә дә сөйләмәскә сүз бирәм, әйдә әйт тизрәк», — ди һәм бу ир: «Мин көндә йомырка салам, ләкин моны башкалар белер дип синнән яшерә идем», — дип, ятактан йомырка китереп чыгара.

Бу хатын иренең әйткән серен күршеләргә сөйләмичә булдыра алмый. Ире эшкә китү белән яшерен серне таратып та

сала. Ир эштән кайтканчы «сер» падишаһка ук барып җитә һәм падишаһ җәһәт кенә бу ирне үзенә чакыртып ала да, эшнең нәрсәдә икәнлеген сорый башлый. Бу ир барчасын да падишаһка бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Падишаһ моны ишетеп рәхәтләнеп көлә дә, чүлмәк тулы алтынны бу иргә калдыра.

## 🕮 Зарланудан һәм аз шөкер итүдән саклан!

Тормышыңны канәгатьлек белән нурландыр! Зарланудан һәм аз шөкер итүдән саклан, әгәр дә иреңнең хәле турында соралсаң, беркайчан да уфтанудан башлама.

عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ عَمْرِو أَنَّ نَبِىَّ الله ﷺ قَالَ: «لاَ يَنْظُرُ الله إِلَى امْرَأَةٍ لاَ تَشْكُرُ لِزَوْجِهَا وَهِىَ لاَ تَسْتَغْنِى عَنْهُ» [ أخرجه الحاكم و قال: صحيح الإسناد و وافقه الذهبي ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамрдан رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иренә шөкер итмәүче (канәгать булмаучы) һәм ирендә үзенең бернинди дә хаҗәте юк дип белгән хатын-кызга, Аллаһ тәгалә карамый!».***

Икенче риваятьтә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Фасикълар алар Җәһәннәм әһелләре».*** Сорадылар: «Әй расүл Аллаһ! Кемнәр алар фасикълар?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызлар».*** Әйттеләр: «Әй расүл Аллаһ! Алар безнең аналарыбыз, кызларыбыз һәм апа-сеңлеләребез түгелмени?». Пәйгамбәребез ﷺ аларга: ***«Әйе, шулай. Ләкин әгәр дә аларга нәрсә булса да бирсәң — шөкер итмиләр (канәгать булмыйлар), ә инде авырлык яки бәла-каза төшсә — сабыр итмиләр»,*** — диде[10].

Монда шулай ук, Ибраһим عليه السلام хакындагы мәшһүр кыйссаны китерергә мөмкин.

Ибраһим عليه السلام улы Исмәгыйльнең عليه السلام хәл-әхвәлләрен белешергә дип Мәккәгә килгәч, аны йортында тапмады һәм Исмәгыйльнең хатыныннан аның кайдалыгын сорагач, хатыны: «Ул безнең өчен ашарга берәрнәрсә булса да алып кайтырга китте», — диде.

10 Мүснәд Әхмәд (шәйх Әлбәний сахих диде)

Аннан соң Ибраһим عليه السلام ничек яшәүләрен һәм хәлләре нинди икәнлеге турында сорады һәм ул: «Начар, чөнки без мохтаҗлык кичерәбез һәм фәкыйрьлектә яшибез!», — диде вә аңа зарлана башлады. Ибраһим عليه السلام әйтте: «Ирең кайткач, аңа миннән сәлам җиткер һәм ул ишегенең бусагасын алмаштырсын дип әйт».

Исмәгыйль عليه السلام кайткач, нәрсәдер сизгән кебек булды һәм: «Безгә кем булса да килдеме?», — дип сорады. Хатыны: «Әйе, безгә бер карт килде, ул синең турында сорады һәм мин аңа ул кызыксынган нәрсәләр турында сөйләдем, ә аннан соң ул безнең ничек яшәгәнебез турында сорады һәм мин безнең мохтаҗлык кичергәнне һәм фәкыйрьлектә яшәгәнне сөйләдем», — диде. Исмәгыйль عليه السلام: «Ул сиңа нинди булса да нәсыйхәт бирдеме?», — дип сорады. Ул: «Әйе, ул сиңа сәлам әйтте һәм ишегеңнең бусагасын алыштырсын дип әйтергә кушты», — диде. Исмәгыйль عليه السلام: «Бу минем әтием һәм ул миңа синең белән аерылышырга кушты, үзеңнең гаиләңә кайт», — диде.

Аннан соң ул аның белән аерылышты һәм (җөрхем кабиләсеннән булган) башка хатынга өйләнде. Ибраһим عليه السلام Аллаһ теләгән кадәр вакыт алардан аерым торды, ә аннан соң алар янына килде, ләкин тагын Исмәгыйльне عليه السلام очратмады. Хатыныннан аның турында сораша башлады, ә ул: «Ул безгә ашарга берәрнәрсә булса да алып кайтырга китте», — дип әйтте. Ибраһим عليه السلام аннан аларның ничек яшәүләре һәм хәлләре нинди икәнлеге турында сорый башлады һәм ул: «Безнең барысы да әйбәт һәм барысы да җитә», — дип әйтте, аннан соң Аллаһ тәгаләгә шөкер итте. Ибраһим عليه السلام: «Сез нәрсә ашыйсыз?», — дип сорады. Ул: «Ит», — диде. Ибраһим عليه السلام: «Ә нәрсә эчәсез?», — дип сорады. Ул: «Су», — диде. Һәм шул вакытта Ибраһим عليه السلام: «Әй Аллаһ, аларның итләрен һәм суларын бәрәкәтле ит!», —диде. Аннан соң Ибраһим عليه السلام аңа: «Ирең кайткач, аңа миннән сәлам җиткер һәм ишегенең бусагасын ныгытсын дип әйт», — диде. Исмәгыйль عليه السلام кайткач: «Сезгә кем булса да килдеме?», — дип сорады. Аның хатыны: «Әйе, безгә күркәм карт килде», — диде, аннан соң ул аны

мактады һәм: «Ул миннән синең турында сорады һәм мин аны кызыксындырган нәрсәләр турында сөйләдем, аннан соң ул миннән безнең ничек яшәгәнне сорады һәм мин аңа барысы да яхшы икәнлеген әйттем», — диде. Исмәгыйль عليه السلام: «Ул сиңа нинди булса да нәсыйхәт бирдеме?», — дип сорады. Ул: «Әйе, ул сиңа сәлам әйтте һәм ишегеңнең бусагасын ныгыт дип әйтергә кушты», — диде. Исмәгыйль عليه السلام: «Бу минем әтием, ә бусага — ул син һәм ул миңа синең белән аерылмаска кушты», — диде.

## Әсмә кебек бул!

Әбү Бәкернең رضي الله عنه кызы Әсмә радый Аллаһу ганһә Ислам тарихында барча хатын-кызларга да ир белән мөгамәлә итүдә үрнәк булып калды.

Бухари вә Мүслимдә килгән хәдисләрдә Әсмә радый Аллаһу ганһә риваять кылып болай диде: «Зүбәйр бин Гауүәм رضي الله عنه миңа өйләнгәндә, аның коедан су алырга булган дөясеннән һәм атыннан башка, җирлегендә бернинди малы да, хезмәтче колы да һәм башка бернәрсәсе дә юк иде. Мин аның атына ашарга бирә идем, коедан су ала идем, су алыр өчен (үгез тиресеннән ясала торган) зур чиләк тегә идем һәм камыр баса идем. Ләкин мин ипине бик яхшы пешерә белмәгәнлектән, безгә ипине, хөрмәткә лаеклы күрше әнсар хатыннары пешерә иделәр. Пәйгамбәребез ﷺ Зүбәйргә бүлеп биргән өч чакрым ераклыктагы җирдән хөрмә төшләрен җыеп, мин үземнең баш өстемдә ташый идем. Бервакыт, мин шулай баш өстемдә хөрмә төшләре алып барганда, бер төркем әнсар белән бергә пәйгамбәребезне ﷺ очраттым. Ул мине чакырып алды да, (дөясенә) утыртырга теләп: ***«Их, их»,*** — диде. Мин Зүбәйрнең көнчеллеген белеп, ир-атлар белән бергә барырга оялдым, чөнки Зүбәйр иң көнчел кешеләрнең берсе иде. Пәйгамбәребез ﷺ минем оялганымны аңлап, юлын дәвам итте. Мин инде кайткач Зүбәйргә: «Мин баш өстемдә хөрмә төшләре алып барганда бер төркем сахәбәләр белән

пәйгамбәребезне ﷺ очраттым. Ул мине утыртыр өчен үзенең дөясен җиргә чүгәләтте, ләкин мин синең көнчеллегеңне белеп утырырга оялдым», — дидем. Зүбәйр миңа: «Аллаһ белән ант итәм! Синең баш өстеңдә хөрмә төшләре күтәреп баруыңа караганда пәйгамбәребезнең ﷺ дөясенә утырып кайтуың миңа күпкә хәерлерәк булыр иде», — диде.

Әбү Бәкер ﵁ миңа ат карап торыр өчен бер хезмәтче җибәргәнчегә кадәр, мин шулай ук эшли торган булдым. Ул хезмәтче җибәреп мине азат иткән кебек булды»[11].

## Иреңнең кадерен бел!

Ирнең йорттагы урыны зур. Шуның өчен дә һәрвакытта да аның белән йортта да, вә балаларың каршында да аны кадерләп вә ихтирам итеп кенә мөгамәлә кыл. Иреңне ихтирам итүең — үзеңнең ихтирамыңны гына арттыра, ә аны кадерләвең — үзеңнең кадереңне генә үстерә.

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَمْرٍو أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «الدُّنْيَا مَتَاعٌ وَخَيْرُ مَتَاعِ الدُّنْيَا الْمَرْأَةُ الصَّالِحَةُ» [ مسلم ١٤٦٧ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөнья ул — ләззәтлек һәм андагы иң хәерле ләззәтлек — изге хатын».***

عن أَبي هريرة ﵁ عن النَّبيّ ﷺ قَالَ: «لَوْ كُنْتُ آمِراً أَحَداً أَنْ يَسْجُدَ لأَحَدٍ لأَمَرْتُ المَرأَةَ أَنْ تَسْجُدَ لِزَوجِهَا» [ رواه الترمذي ١١٥٩ وَقالَ حديث حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр миңа кешеләрдән кемгә дә булса икенче берсенең каршында сәҗдә кылырга әмер итәргә туры килсә иде, мин әлбәттә, хатынга иренә сәҗдә кылырга әмер итәр идем!».***

عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ الله عَنْها قَالَتْ: «سَأَلْتُ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: أَيّ النَّاس أَعْظَم حَقًّا عَلى المَرْأَة؟ قَالَ: «زَوْجهَا» قُلت: فَأَيّ النَّاس أَعْظَم حَقًّا عَلى الرَّجُل؟ قَالَ: «أمّه» [ المستدرك على الصحيحين للحاكم ]

11 Бухари (5224)

Мәгънәсе: Гаишә р.г. әйтте: «Мин пәйгамбәребездән ﷺ: «Хатын-кыз өчен иң олуг хокуклы кеше кем?», — дип сорадым. Ул миңа: ***«Ире»,*** — диде. Шуннан соң мин аннан: «Ә ират өчен иң олуг хокуклысы кем?», — дидем. Ул миңа: ***«Әнисе»,*** — диде.

***Хикәя:*** Бер хатын гади генә утын кисүче иргә кияүгә чыга. Ире эштән кайтканда ашарына әзерләп, аны гел дә капка янында каршы алып булыша торган була. Ире ашап йокларга ятакка яткач, ул йоклап киткәнчегә кадәр аның янында утыра. Моны кызы күреп, әнисеннән: «Әнием, син нигә гел дә шулай эшлисең?», — дип сорагач, әнисе аңа: «Синең әтиең башка кешеләр өчен гади утын кисүче генә, ә безнең йорт эчендә ул — йортның падишаһы, шуның өчен дә мин аның белән патшалар кебек мөгамәлә итәм», — дип җавап бирә.

## Битәрләүче булма!

Әгәр дә ireңә нинди дә булса игелек кылсаң, яки мал һәм башка нәрсә белән ярдәм итсәң, кылган эшең өчен аны битәрләмә, чөнки битәрләү — талакка сәбәп була.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُبْطِلُوا صَدَقَاتِكُمْ بِالْمَنِّ وَالْأَذَى) البقرة: ٢٦٤

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Биргән садакаларыгызны миннәт[12] кылып яки рәнҗеп биреп савабын юкка чыгармагыз!».**

عنْ أَبِي ذر رضي الله عنه عن النبيِّ ﷺ قَالَ: «ثلاثةٌ لا يُكَلِّمُهُمُ اللهُ يَوْمَ القِيَامَةِ وَلاَ يَنْظُرُ إِلَيْهِمْ وَلاَ يُزَكِّيهِمْ وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ» ... منهم: «وَالمنَّانُ» [ مسلم ١٠٦ ]

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаh тәгалә Кыямәт көнендә өч төр кеше белән сөйләш-мәс, аларга карамас һәм аларны пакьләмәс һәм аларга каты газап әзерләнгән!»***...Шуларның берсе: ***«Миннәт кылучы»[13].***

12 Берәүгә күрсәткән, эшләнгән яхшылыгын, ярдәмен һәрвакыт искә төшереп, аны битәрләү

13 Ягъни, үзенең изгелекләре белән кешеләрне битәрләүче

## 🕮 Иреңә ярдәм ит!

Әгәр дә Аллаһ тәгалә сине байлык вә мал-мөлкәт белән ризыкландырса, ул байлыктан йортка кирәк-ярак алуда иреңә ярдәм итсәң, сиңа әҗер-савап кына була, иншәАллаһ.

عن زينب الثقفيةِ امرأةِ عبدِ الله بن مسعود رضي الله عَنْهُ وعنها قَالَتْ: قَالَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم: «تَصَدَّقْنَ يَا مَعْشَرَ النِّسَاءِ وَلَوْ مِنْ حُلِيِّكُنَّ» قَالَتْ: فَرَجَعْتُ إِلَى عبد الله بن مسعود فقلتُ لَهُ: إِنَّكَ رَجُلٌ خَفِيفُ ذَاتِ اليَدِ وَإِنَّ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم قَدْ أَمَرَنَا بِالصَّدَقَةِ فَأْتِهِ فَاسأَلْهُ فَإِنْ كَانَ ذلِكَ يُجْزِىءُ عَنِّي وَإلاَّ صَرَفْتُهَا إِلَى غَيْرِكُمْ. فَقَالَ عبدُ اللهِ: بَلِ ائْتِيهِ أنتِ، فانْطَلَقتُ، فَإِذَا امْرَأَةٌ مِنَ الأَنْصار بِبَابِ رسولِ اللهِ صلى الله عليه وسلم حَاجَتي حَاجَتُها، وَكَانَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم قَدْ أُلْقِيَتْ عَلَيهِ المَهَابَةُ، فَخَرجَ عَلَيْنَا بلاَلٌ، فَقُلْنَا لَهُ: ائْتِ رَسُول الله صلى الله عليه وسلمِ فَأخْبِرْهُ أنَّ امْرَأتَيْنِ بالبَاب تَسألانِكَ: أَتُجْزِىءُ الصَّدَقَةُ عَنْهُمَا عَلَى أَزْواجِهِمَا وَعَلى أيْتَام في حُجُورِهِمَا؟ وَلاَ تُخْبِرْهُ مَنْ نَحْنُ، فَدَخلَ بِلاَلٌ عَلَى رَسُول الله صلى الله عليه وسلم فسأله، فَقَالَ لَهُ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم: «مَنْ هُمَا ؟» قَالَ: امْرَأةٌ مِنَ الأنْصَار وَزَيْنَبُ، فَقَالَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم: «أيُّ الزَّيَانِبِ هِيَ ؟» قَالَ: امْرَأةُ عبدِ الله، فَقَالَ رَسُول الله صلى الله عليه وسلم: «لَهُمَا أجْرَانِ: أجْرُ القَرَابَةِ وَأجْرُ الصَّدَقَةِ» [ مُتَّفَقٌ عَلَيهِ ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуднең ﵁ хатыны Зәйнәп әс-Сәкафийә әйтте: «Бервакыт, пәйгамбәребез ﷺ: ***«Әй хатыннар, үз зиннәтләрегездән булса да садака бирегез»,*** — диде. Зәйнәп әйтте: «Һәм моннан соң мин Габдуллаһ бин Мәсгудкә ﵁ кайтып: «Син бай кеше түгел, ә Аллаһның илчесе ﷺ безгә садака бирүне әмер итте, аның янына барып, минем өчен бу (садакаларны сиңа һәм үземнең карамагымда булган ятимнәргә бирсәм) ярыймы икәнен сора, әгәр дә ярамаса, ул вакытта мин (үз акчаларымны) сезгә түгел, ә башкаларга сарыф итәм», — дидем. Ул миңа: «Юк, аның янына үзең барып сора», — диде. Мин киттем, пәйгамбәребезнең ишеге янында әнсарлардан булган бер хатынны очраттым. Ул хатынның да минеке кебек хаҗәт иде. Аллаһ тәгалә тарафыннан кешеләр өчен пәйгамбәребезгә ﷺ карата тирән ихтирам билгеләнгән иде. Бераз вакыт үткәч безнең янга Биләл ﵁ чыкты һәм без аңа: «Пәйгамбәребезгә ﷺ кереп, аның ишеге янында тору-

чы ике хатын үзләренең ирләренә һәм тәрбияләрендә булган ятимнәргә садакаларын бирүләре ярыймы, дип аңардан сора, ләкин безнең кемлегебезне әйтмә», — дип үтендек. Биләл ؓ пәйгамбәребезгә ﷺ кереп без әйтткәнне сорады, ә пәйгамбәребез ﷺ Биләлдән ؓ: ***«Кемнәр алар?»,*** — дип сорады. Биләл ؓ: «Әнсарлардан бер хатын һәм Зәйнәп», — дип җавап бирде. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Кайсы Зәйнәп?»,*** — дип сорады. Биләл ؓ: «Габдуллаһның хатыны», — диде. Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ: ***«Моның өчен аларга икешәр әҗер-савап тиешле: берсе — кардәшлек бәйләнешләрен тоткан өчен, ә икенчесе — садака биргән өчен»,*** —диде».

Шулай ук Бухарида 1467нче сан белән килгән икенче риваятьтә, Үммү Сәләмәһ радый Аллаһу ганһә пәйгамбәребездән ﷺ: «Мин Әбү Сәләмәһнең балаларына (акчаларымны) сарыф итсәм, миңа әҗер-савап булырмы, чөнки алар бит минем дә балаларым?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Аларга сарыф ит һәм сиңа моның өчен әҗер-савап булыр»,*** — диде.

## Иреңә изгелектә ярдәмләш!

(وَتَعَاوَنُوا عَلَى الْبِرِّ وَالتَّقْوَى) المائدة: ٢

Мәгънәсе: **«Бер-берегезгә изгелектә вә тәкъвалыкта ярдәмләшегез».**

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ؓ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «رَحِمَ اللهُ رَجُلًا قَامَ مِنَ اللَّيْلِ فَصَلَّى وَأَيْقَظَ امْرَأَتَهُ فَإِنْ أَبَتْ نَضَحَ فِي وَجْهِهَا الْمَاءَ رَحِمَ اللهُ امْرَأَةً قَامَتْ مِنَ اللَّيْلِ فَصَلَّتْ وَأَيْقَظَتْ زَوْجَهَا فَإِنْ أَبَى نَضَحَتْ فِي وَجْهِهِ الْمَاءَ» [ أبو داود ١٣٠٨ تحقيق الألباني: حسن صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Төнлә торып намаз укыганнан соң хатынын намазга уяткан һәм хатыны да намаз укыган, ә инде хатыны тормаса аның битенә су сипкән ир-атка — Аллаһ рәхимле була. Шулай ук төнлә торып намаз укыганнан***

***соң ирен уяткан һәм ире дә намаз укыган, ә инде ире тормаса аның битенә су сипкән хатын-кызга — Аллаһ тәгалә рәхимле була».***

عَنْ أَبِى سَعِيدٍ وَأَبِى هُرَيْرَةَ رَضِي الله عَنْهُمَا قَالاَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «إِذَا أَيْقَظَ الرَّجُلُ أَهْلَهُ مِنَ اللَّيْلِ فَصَلَّيَا أَوْ صَلَّى رَكْعَتَيْنِ جَمِيعًا كُتِبَا فِى الذَّاكِرِينَ وَالذَّاكِرَاتِ» [ أَبُو داود ١٣٠٩، صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйд һәм Әбү Һүрайралардан риваять ителүенчә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр ир-ат төнлә белән үзенең хатынын уятса һәм алар намаз укысалар, яки: ... аның белән бергә ике ракәгать намаз укыса, алар Аллаһны күп зикер итүче ирләр һәм хатыннар арасында язылырлар».***

Госман ән-Нәһдий болай диде: «Мин Әбү Һүрайраны җиде көн /яки җиде тапкыр/ кунак иттем. Ул хатыны һәм хезмәтчесе белән төннәрне өчкә бүлә торган иделәр. Төннең беренче өлешендә берсе намаз укый һәм икенче өлешенә икенчесен уята, икенчесе төннең икенче өлешен намаз белән уздыргач, өченче өлешенә өченчесен уята торган иде».

Бер ир хатынын изгелектә ярдәм итүдә мактап: «Мин төнлә белән кайчан гына торсам да, хатыным миңа таһәрат алыр өчен комган белән җылы су әзерләп куйган була иде инде», — дип әйтә торган иде.

## 🕮 Иреңнең рөхсәтеннән тыш ураза тотма!

Ураза, Аллаһ белән бәндә арасындагы сер булып тора. Әгәр дә нәфел уразасы тотырга теләсәң, ireңнән рөхсәт сора, чөнки бу күңелләрне өлфәтләндерә.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِي الله عَنْهُ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى الله عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «لا تَصُومُ الْمَرْأَةُ وَبَعْلُهَا شَاهِدٌ إِلا بِإِذْنِهِ» [ البخاري ٥١٩٢ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ире янында булганда, хатын-кызга иренең рөхсәтеннән башка ураза тоту ярамый».***

Ибен Хәҗәр шушы ук мәгънәдә килгән Бохаридагы 5195нче хәдиснең аңлатмасында: «Күпчелек гыйлем әһелләренең әйтүенчә, бу риваять хатын-кызга нәфел уразасын иренең рөхсәтеннән башка тоту хәрам икәнлеген бәян итә», — диде.

Чөнки, әгәр дә ире аның белән якынлык кылырга теләсә, хатыны иренә буйсыну фарыз була, ә инде билгеле булганча нәфел уразалар тоту — фарыз түгел. Шуңа да нәфелгә карaганда фарыз булган ирнең хакын үтәү — әүвәлрәк. Әмма әгәр дә фарыз уразасы булса, яки ире янында булмыйча сәфәрдә булса, әлбәттә рөхсәт сорап тору кирәкми.

Бервакыт, пәйгамбәребез ﷺ янына бер хатын килде дә: «Әй расүл Аллаһ! Минем ирем — Сафүән бин әл-Мүгатталь, мин намаз укысам — ул мине кыйный, ураза тотсам — мәҗбүри уразамны боздырта һәм ул иртәнге намазны кояш чыккач кына укый», — дип зарлана башлады. Бу хатынның ире Сафүән ؓ пәйгамбәребез ﷺ янында иде һәм расүлебез ﷺ аннан хатынының әйткән зарлары турында сорагач, Сафүән ؓ: «Әй Аллаһның илчесе! Намаз укыганда мин аны кыйный дип әйтүе, ул бер ракәгъәттә /яки икесендә дә/ бик озын ике сүрә укый һәм мин аны намазда бик озын сүрәләр укудан вә намазны бик озак укудан тыйдым», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аларга: ***«Әгәр дә бер генә сүрә (озын булмаса да) укылса, кешеләргә җитә»,*** — диде. Шуннан соң Сафүән ؓ дәвам итеп: «Ә инде (нәфел) ураза тотканда мин аның уразасын мәҗбүри боздырам дип әйтүе, хакыйкатьтә, мин яшь вә бик дәртле һәм сабыр итә алмыйм», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аларга: ***«Хатын-кыз иренең рөхсәтеннән тыш ураза тота алмый»,*** — диде. Сафүән ؓ дәвам итеп: «Мин кояш чыккач кына иртәнге намазны укый дип әйтүе, хакыйкатьтә, безнең йортыбызга бу билгеле нәрсә, чөнки без төнлә белән эшлибез һәм төн ахырында ятсак, кояш чыккач кына уянабыз», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Уянгач та намазыңны укы»,*** — диде[14].

14 Әбү Дауыд (2459 сахих)

## 🕮 Урамга күп чыгудан саклан!

Синең йортың ул кечкенә мәмләкәт. Күпчелек вакытыңны йортта үткәрүең, гаиләң өчен бәхет вә сәгадәтнең үзәге.

(وَقَرْنَ فِي بُيُوتِكُنَّ وَلَا تَبَرَّجْنَ تَبَرُّجَ الْجَاهِلِيَّةِ الْأُولَى) الأحزاب: ٣٣

Мәгънәсе: **«Өйләрегездә торыгыз, вә җәһилият заманындагы хатыннар кебек бизәнгән зиннәтләрегезне ят ирләргә күрсәтмәгез».**

عَنْ عَبْدِ اللهِ بن عمر رضي الله عنهما عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «الْمَرْأَةُ عَوْرَةٌ فَإِذَا خَرَجَتِ اسْتَشْرَفَهَا الشَّيْطَانُ» [ الترمذي ١١٧٣، صحيح ]

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кыз ул гаурәт, әгәр дә урамга чыкса, шәйтан аны ят ир-атларга зиннәтләп күрсәтә /яки, аны аздыра һәм башкаларны да ул хатын белән аздыра/».***

Кайбер гарәп китапларында: «Бер изге сәләфләрдән булган хатын-кыз гомерендә ике тапкыр гына йортыннан чыкты, берсе — кияүгә чыккач атасының йортыннан иренең йортына күчте, ә икенчесе — вафат булгач, иренең йортыннан кабергә күчте», — диелде.

Зүбәйр бин Гауүәм ﵁ бик тә чибәр Гатикәгә өйләнде һәм ул хатыннарына бик тә көнчел иде. Гатикәнең алдагы ирләре вафат булганнан соң Зүбәйргә кияүгә чыккач, гадәттәгечә мәчеткә намазга йөри торган булды. Хатынының мәчеткә намазга йөрүен Зүбәйр бик тә авыр күтәрә иде, шуңа карамастан ул пәйгамбәребезнең ﷺ ***«Хатыннарыгызны мәчеткә йөрүдән тыймагыз»,*** — дигән хәдисенә каршы килеп, аны намазга йөрүдән дә тыясы килмәде. Бервакыт, кичке намаздан соң хатыны мәчеттән кайтырга чыккач, Зүбәйр кеше танымаслык итеп киемнәрен бөркәнде дә, хатынының артыннан килеп кулы белән шәп итеп кенә арт санына сукты да, йөгереп качты. Бу вакыйгадан соң, хатыны Гатикә, мәчеткә йөрми башлады. Зүбәйр аннан: «Син мәчеткә йөрмисеңме әллә хәзер Гатикә?»,

— дип сорагач, хатыны: «Мин элек мәчеткә йөргәндә кешеләр яхшы иде, ә хәзер алар бозылды?!», — дип җавап бирде[15].

## Хиҗәбсез һәм хушбуйланып урамга чыгудан саклан!

Әгәр дә хиҗәбсез һәм гаурәтләрне күрсәтеп йөрү кешенең алга китешлеген вә мәдәниятлеген (урысча цивилизацияле-ген) күрсәтә торган булса, хайваннар иң цивилизацияле җан ияләре булырлар иде.

عن أَبي هريرة رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رسولُ الله صلى الله عليه وسلم: «صِنْفَانِ مِنْ أهْلِ النَّارِ لَمْ أرَهُمَا: قَومٌ مَعَهُمْ سِيَاطٌ كَأذْنَابِ البَقَرِ يَضْرِبُونَ بِهَا النَّاسَ، وَنِسَاءٌ كَاسِيَاتٌ عَارِيَاتٌ مُمِيلاَتٌ مَائِلاَتٌ، رُؤُوسُهُنَّ كَأَسْنِمَةِ البُخْتِ المائِلَةِ لاَ يَدْخُلْنَ الجَنَّةَ وَلاَ يَجِدْنَ رِيحَهَا وإنَّ رِيحَهَا لَيُوجَدُ مِنْ مَسِيرَةِ كَذَا وَكَذَا» [ رواه مسلم ٢١٢٨ ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Җәһәннәм әһелләренең ике төрен мин хәзерге вакытта әле күрмим: (Берәүләре) кешеләрне кыйный торган үгез койрыкларына охшаш камчылы ирләр, ә (икенчеләре) шул ук вакытта киенгәннәр дә, шәрәләр дә, тайпылганнар да һәм тайпылдыручылар да хатыннар, аларның башлары дөянең асылынып торган өркәчләре шикелле. Мондый хатын-кызлар Җәннәткә кермәсләр һәм аның хуш исен дә сизмәсләр, ә аның хуш исе бик-бик ерактан сизелер».***

عَنْ زَيْنَبَ امْرَأَةِ عَبْدِ الله قَالَتْ: قَالَ لَنَا رَسُولُ الله صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «إِذَا شَهِدَتْ إِحْدَاكُنَّ الْمَسْجِدَ فَلا تَمَسَّ طِيبًا» [ مسلم ٤٤٣ ]

Мәгънәсе: Зәйнәб әс-Сакафия риваять итүенчә: «Безгә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегезнең (хатын-кызларның) мәчеткә барасы килсә, хушбуй кулланма-сын!».***

15 «Әл-Исабәһ»

## 🕮 Иреңә тугры бул!

Тугрылык, ул бөтен җимеше дә тәмле булган таза вә яхшы агач кебек. Шуңа да тугрылыксыз гаиләнең көннәре санаулы гына була.

Гомәр бин Габдулгазиз хәлиф булгач, хатыны — Фатыймә бинт Габдулмәликкә барча зиннәт байлыкларын да мөселманнарның казнасы булган «бәйтүл-малга» тапшырырга кушты. Хатыны иренең әмерен ишетү белән, барча зиннәт байлыкларын «бәйтүл-малга» тапшырырга ашыкты.

Еллар узып, Гомәр бин Габдулгазиз вафат булганнан соң, хәлифлек Фатыймә бинт Габдулмәликнең туганы — Язид бин Габдулмәликкә күчте. Язид хәлиф булгач апасына: «Син элек «бәйтүл-малга» тапшырган зиннәт байлыкларың барчасы да исән, әгәр дә аларны аласың килсә, мин сиңа аларны бирәм», — диде. Апасы аңа: «Хакыйтьтә, минем ирем — мөэминнәрнең әмире Гомәр бин Габдулгазиз, үзе булган вакытта ул зиннәт байлыкларының «бәйтүл-малда» булуын яхшы күрде һәм мин аңа буйсынып риза булдым. Мин иремә тере вакытында да тугры булдым һәм вафат булгач та аңа тугры булып калачакмын», — дип җавап бирде.

## 🕮 Иреңнең рөхсәтеннән тыш йортка һичкем дә кермәсен һәм иреңә каршы сине беркем дә бозмасын!

Изге-салиха хатын, иренең рөхсәтеннән тыш йортка һичкемне дә кертми. Булсын ул күрше, туган-тумачалар яки әшнәләр, алар барсы да ирнең рөхсәте белән генә йортка керергә тиешләр.

عن أبي هريرة رِضْيِ الله عنه: أَنَّ رسُول الله ﷺ قال: «لاَ يَحِل لِلمَرْأةِ أَنْ تَصُومَ وَزَوْجُهَا شَاهِدٌ إِلاَّ بِإذْنِهِ وَلاَ تَأْذَنَ فِي بَيْتِهِ إِلاَّ بِإِذْنِهِ» [ متفق عَلَيْه ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ире янында булганда, хатын-кызга иренең рөхсәтеннән тыш***

***ураза тоту ярамый, шулай ук, иренең рөхсәтеннән тыш аның йортына беркемне дә кертергә тиеш түгел».***

Икенче риваятьтә: ***«Дөреслектә, сезнең хатыннарыгызда һәм хатыннарыгызның сездә хаклары бар. Сез алардан үзегезгә ошамаган кешеләрне түшәгегезгә утыртмаска һәм үзегез күрергә теләмәгән кешеләрне йортларыгызга кертмәүләрен таләп итәргә хакыгыз бар»,*** — диелде[16].

عن أَبي هرِيرة رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «مَنْ خَبَّبَ زَوْجَةَ امْرِئٍ أَوْ مَمْلُوكَهُ فَلَيْسَ مِنَّا» [ أبو داود ٥١٧٠، صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иратның хатынын яки колын аздыручы, бездән түгел!».***

## Гыйлем алуда тырыш бул!

Аллаһ ризалыгы өчен гыйлем алуда тырыш бул, чөнки гыйлем, сине ирең каршында бизи.

قَالَتْ عَائِشَةُ رضي الله عنها: «نِعْمَ النِّسَاءُ نِسَاءُ الأَنْصَارِ لَمْ يَكُنْ يَمْنَعُهُنَّ الْحَيَاءُ أَنْ يَتَفَقَّهْنَ فِى الدِّينِ» [ مسلم ٣٣٢ ]

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһ ганһә әйтте: ***«Иң күркәм хатыннар — әнсар хатыннары. Дин гыйлеме алуда алар оялмый иделәр».***

Хәзерге заманаларда киресенчә, хатын-кызлар дөньяви гыйлем алуда оялмыйлар. Мәчетләрдә вә мәдрәсәләрдә укыган хатын-кызларны түбәнсетеп, аларның дөньяви гыйлеме булмаса томанага, наданга чыгаралар, ә үзләре әлифне таяк дип тә белмиләр. Мондый хатыннар көне-төне ят ирләр белән чуалып, имеш «бизнес леди» «бизнес уомен» булабыз дип, үзләренең гаилә тормышларын да кора алмыйлар. Күпме татар кызлары диннәрен белмичә, кәферләргә ияреп үзләренең намусларын шәйтанга сатты, Аллаһу мүстәган. Алар бу дөньяда да хәсрәттә, кайгыда һәм ахирәттәгесен

16 Тирмизи (1163)

Аллаһу әгъләм. Аллаһ тәгалә барчабызга да һидәят бирсен һәм Ислам динебездә аякларыбызны ныклы кылсын!

Бухарида 101нче сан белән килгән икенче риваятьтә, хатын-кызлар пәйгамбәребезгә ﷺ килеп «безгә дә гыйлем алуда бер көн билгеләә» дигәч, расүлебез ﷺ аларны җыеп вәгазь кылды.

***Әсәр:*** Габдуллаһ бин Әбү Үәдәгаһ үзенең остазы булган Сәгыйд бин әл-Мүсәийбнең кызына өйләнгәч, Сәгыйд бин әл-Мүсәийб Габдуллаһка кызын алып килде дә: «Әй Габдуллаһ! Бу кызым хәзер инде синең хатының. Аллаһ белән ант итәм! Син аны күп ураза тотучы, күп намаз укучы һәм дә Аллаһның китабын вә расүлебезнең ﷺ сөннәтен яхшы белүче итеп хатынлыкка аласың. Аның белән мөгамәлә итүдә Аллаһка тәкъва бул! Әгәр дә бу кызда син яратмаган нәрсә булса, сиңа аны нәсыйхәт итүдә мин синең остазың булуы комачауламасын!», — дип кызын миңа калдырды да, чыгып китте. Соңырак Габдуллаһ әйтә торган иде: «Аллаһ белән ант итәм! Бу хатыннан да яхшырак Аллаһның китабын вә расүлебезнең сөннәтен белүче һәм тәкъва хатын-кыз күрмәдем. Әгәр дә миңа һәм дә башка гыйлем ияләренә берәр авыр мәсьәлә килеп чыкса, мин аннан сорый торган идем һәм ул мәсьәләгә җавап таба идем».

## 🕮 Иреңә һәм балаларыңа әһәмиятле бул!

Ирне һәм балаларны тәрбия кылу, хатын-кызның иң хәерле гамәлләренең берсе. Чөнки, иренең һәм балаларының уңышка ирешүе — аның да уңышка ирешүе булып тора. Шуңа да гаиләңдә иң хәерле хатын вә иң хәерле ана булырга тырыш!

عن ابن عمر رضي الله عنهما عن النَّبيِّ ﷺ قَالَ: «كلكم رَاعٍ وَكُلُّكُمْ مَسْؤُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ: وَالأمِيرُ رَاعٍ، والرَّجُلُ رَاعٍ عَلى أهْلِ بيتِهِ، وَالمَرْأةُ رَاعِيةٌ عَلى بَيْتِ زَوْجِها وَوَلَدِهِ، فَكُلُّكُمْ رَاعٍ وَكُلُّكُمْ مَسْؤُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ» (مُتَّفَقٌ عَلَيهِ)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гомәрдән رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезнең һәркайсыгыз көтүче һәм сезнең һәркайсыгыз үз көтүлеге өчен җавап бирә: Әмир —***

***ул көтүче, ир кеше гаиләсе өчен көтүче, хатын-кыз иренең йорты һәм аның балалары өчен көтүче. Шулай итеп, сезнең һәркайсыгыз көтүче һәм һәркайсыгыз үз көтүлеге өчен үзе җавап бирә».***

Җәбир бин Габдуллаһ әйтте: «Әтием җиде яки тугыз кыз бала калдырып вафат булып киткәч, мин элек кияүдә булган хатын-кызга өйләндем. Моннан соң пәйгамбәребез ﷺ мине күреп: ***«Өйләндеңме әллә Җәбир?»,*** — дип сорады. Мин: «Әйе», — дидем. Пәйгамбәребез ﷺ миннән: ***«Кызгамы әллә кияүдә булгангамы?»,*** — дип сорады. Мин: «Кияүдә булганга», — дип җавап бирдем. Шуннан соң расүлебез ﷺ миңа: ***«Әгәр дә кыз булганга өйләнеп аның белән шаярсаң вә ул да синең белән шаярса, аны көлдерсәң вә ул да сине көлдерсә иде»,*** — диде. Мин расүлебезгә ﷺ: «Минем әтием — Габдуллаһ, бик күп кыз балалар калдырып вафат булды һәм мин алар кебек үк (эш эшләргә әле өйрәнмәгән) яшь кызга өйләнәсем килмәде. Шуңа да аларны тәрбияли вә карый ала торган хатынга өйләндем», — дидем. Пәйгамбәребез ﷺ миңа: ***«Аллаһ сиңа бәрәкәт бирсен!»,*** — диде[17].

Мүслимдә 2630нчы сан белән килгән хәдистә, Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Бервакыт, миңаниндидер бер фәкыйрь хатын кулына ике кыз күтәреп килде һәм мин аңа өч хөрмә бирдем, ул берәр хөрмәне кызларының һәрберсенә бирде, ә өченчесен үзе ашарга теләп авызына китерде, ләкин шунда кызлары янә аңардан ашарга сорый башладылар һәм ул бу хөрмәне аларга бүлеп бирде. Аның бу гамәле мине сокландырды һәм мин бу хакта пәйгамбәребезгә ﷺ сөйләдем, ул: ***«Дөреслектә, Аллаһ моның өчен аңа Җәннәтне вәҗиб кылды / яки аны уттан азат итте/!»,*** — диде.

Әнәс ؓ риваять итеп болай диде: «Мин кечкенә вакытта балалар белән уйнаганда, минем яныма пәйгамбәребез ﷺ килде дә, безгә сәлам бирде. Шуннан соң, ул миңа йомыш кушты һәм мин әнием янына өйгә соңга калып кайттым. Әнием миннән: «Нишләп син соңга калдың?», — дип сорагач, мин: «Пәйгамбәребез ﷺ мине бер йомыш белән җибәргән иде,

17 Бухари (5367)

шуңа соңладым», — дип җавап бирдем. Ул миннән: «Нинди йомыш иде соң ул?», — дип сорады. Мин: «Ул — сер», — дидем. Шуннан соң, әнием миңа: «Пәйгамбәребезнең ﷺ серен һичкемгә дә сөйләмә», — диде.

## 🕮 Сәбәпсез талак сорама!

Ир белән хатынның бергә тору мөмкинлеге булмаганда гына, соңгы юл булып талак чарасы кала. Талак, иблискә иң сөйкемле гамәлләрнең берсе булып тора. Шуңа да, сәбәпсез яки кечкенә генә нәрсәгә үпкәләп талак сорау тыела.

عن أَبِي هريرة رَضِيَ الله عَنْهُ عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم أَنَّهُ قَالَ: «الْمُنْتَزِعَاتُ وَالْمُخْتَلِعَاتُ هُنَّ الْمُنَافِقَاتُ» [ النسائي ٣٤٦١، صحيح ]

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ирләреннән сәбәпсез талак һәм хульга[18] сораучы хатын-кызлар — монафикълар».***

عَنْ ثَوْبَانَ رَضِيَ الله عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ الله صلى الله عليه وسلم: «أَيُّمَا امْرَأَةٍ سَأَلَتْ زَوْجَهَا طَلاَقًا فِى غَيْرِ مَا بَأْسٍ فَحَرَامٌ عَلَيْهَا رَائِحَةُ الْجَنَّةِ» [ أبو داود ٢٢٢٦، صحيح ]

Мәгънәсе: Сәүбән бин Бүҗдәдтән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә хатын-кыз сәбәпсез иреннән талак сорый икән, ул хатынга Җәннәт исе хәрам булыр».***

Сәбәпсез талак сораучы хатыннарның монафикълар дип әйтелүе, чөнки алар тыштан караганда ирләренә буйсынган булып, күңелләре белән ирләренә буйсынырга теләмичә бер сәбәпсез яки юк-бардан гына талак сорыйлар.

---

18 Әгәр хатын-кыз иренә акча, мал яки башка нәрсә биреп, үзен аеруны сорый икән, һәм ир дә шуңа риза булып аны аера икән, бу «хульга» — дип атала. Икенчә әйткәндә, кол ничек үзен хуҗасыннан сатып алып азат була икән, хатын-кыз да үзен иреннән сатып алып азат итә.

# Йомгаклау

Әлхәмдулилләһ, Аллаһның теләге вә ярдәме илә изге гамәлләр тәмамлана.

Без инде шушында китабыбызны тәмамлыйбыз. Аллаһ Раббыбыз барчаларыбызга да файдалы гыйлемнәр бирсен һәм шул гыйлемнәр белән изге гамәлләр кылырга насыйп итсен!

Йә Аллаһ! Ниятләребезне ихлас кыл һәм гамәлләребезне кабул ит! Ир-атларга салиха хатыннар, хатын-кызларга изге ирләр бир, араларыбызга өлфәт мәхәббәт сал һәм дә игелек-ле балалар белән ризыкландыр!

Хакыйкатьтә, Син ишетүче вә догаларны кабул итүчесең!

# Эчтәлек


Кереш сүз....................3
Ирәңне ничек сайлыйсың?....................8
• Ирең өчен зиннәтлән вә бизән!....................9
Ирәңне җәфалама вә йөдәтмә!....................9
Һәҗәр кебек бул!....................10
Ирәңә елмаеп кара!....................11
Ирәңнең шатлыкларын да, кайгыларын да уртаклаш!....................11
Хәләл ризык кәсеп итүдә ирәңә ярдәмче бул!....................12
Ирәңнән канәгать бул!....................13
Ирәңнең фәкыйрьлегенә сабыр ит!....................14
Ирәңнең кунакларына әһәмиятле бул!....................15
Ирең каршында булган хакны үтәүдә ваемсыз булма!....................16
Ирең чакырса җавап бир һәм аны ачуландырма!....................18
Гомәр رضي الله عنه вакытындагы сөт сатучы кыз кебек бул!....................19
Ирәңә чит хатын-кызларны сыйфатлама!....................19
Исраф кылучылардан булма!....................20
Ирәңнең яшерен серләрен таратма!....................21
Зарланудан һәм аз шөкер итүдән саклан!....................22
Әсмә кебек бул!....................25
Ирәңнең кадерен бел!....................26
Битәрләүче булма!....................27
Ирәңә ярдәм ит!....................28
Ирәңә изгелектә ярдәмләш!....................29
Ирәңнең рөхсәтеннән тыш ураза тотма!....................30
Урамга күп чыгудан саклан!....................31
Хиҗәбсез һәм хушбуйланып урамга чыгудан саклан!....................32
Ирәңә тугры бул!....................33
Ирәңнең рөхсәтеннән тыш йортка һичкем дә кермәсен һәм ирәңә каршы сине беркем дә бозмасын!....................34
Гыйлем алуда тырыш бул!....................35
Ирәңә һәм балаларыңа әһәмиятле бул!....................36
Сәбәпсез талак сорама!....................38
Йомгаклау....................39